СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон,
422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ
Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы,
422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39. E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

25.03.2024　　　　с. Верхний Услон　　　　№ 43-580

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу сәбәпле даими рәвештә бер мәртәбә бүләкләү нигезендә муниципаль хезмәткәргә, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында.

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Муниципаль берәмлек вәкиллекле органы депутатының, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Югары Ослан муниципаль районы Уставы, Югары Ослан муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмә нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Советының 2022 елның 08 августындагы 25-340 номерлы карары белән расланган тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә даими рәвештә бер мәртәбә бүләкләү нигезендә муниципаль хезмәткәргә, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыкканга бәйле рәвештә даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына түләү тәртибе турында нигезләмәгә (1 нче кушымта) түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

«11. Дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында мәгълүмат социаль өлкәдә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформада һәм ЭЦП операторы билгеләгән форматлар нигезендә урнаштырыла»;

1.2. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыкканга бәйле рәвештә даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына түләү

тәртибе турында нигезләмәгә (2 нче кушымта) түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:
«13. Дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында мәгълүмат социаль өлкәдә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформада һәм ЭЦП операторы билгеләгән форматлар нигезендә урнаштырыла».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Совет рәисе урынбасары,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы урынбасары С.В. Осянин